Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 апрель, 2023 ел № 226

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 20 маендагы 77 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 өлешнең 2.8 пунктында «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов